ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.02.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№631**

Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 15 августындагы 671 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 15 сентябрендәге 695 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча.

1.2. «Зеленодольск муниципаль районының физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының, эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификациясе төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2024 елның 19 июлендәге 1898 номерлы;
- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге 1898 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 06 мартындагы 582 номерлы;
- от 27.10.2025 № 2960 «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 1898 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 27 октябрендәге 2960 номерлы;

3. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлегенә Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 24 февралендәге
631 номерлы карарына
1 нче кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ МУНИЦИПАЛЬ ОЕШМАЛАРЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Зеленодольск муниципаль районының физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең (алга таба - физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы) окладларын формалаштыру тәртибен , компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын тәгаенлый.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы - физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең шартларын һәм күләмнәрен, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән база (вазыйфаи) окладларының күләмнәрен дә кертеп, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады - тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче һөнәре буенча яки җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы хезмәткәрләренең оклады , компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, бер календарь ай өчен билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын асылда эшләнгән вакытта башкарган өчен физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы хезмәткәре хезмәте өчен түләүнең билгеләп куелган күләме;

эш хакы (хезмәте өчен түләү) - физик культура һәм спорт муниципаль оешма хезмәткәренең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле рәвештә , компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен кертеп, хезмәте өчен түләү;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

1.3. Физик культура һәм спорт муниципаль оешма хезмәткәренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, авыл хуҗалыгы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба – физик культура хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре) эш хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

вазыйфаи окладыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Физик культура һәм спорт муниципаль оешма хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яисә белем турындагы документлар торгызылуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, тармакның аерымлык билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук аның өчен уртача хезмәт хакы сакланып калган башка чорларда хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокук барлыкка килгәндә, аның хезмәте өчен түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Физик культура һәм спорт муниципаль оешма җитәкчеләре:

физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре билгеләнә торган белем алу һәм эш стажын (белгечлек буенча эшләрне, билгеле бер вазыйфада) һәм башка нигезләрне тикшерәләр;

ел саен физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

## II. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Айлык база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре | | |

| | | |
|---|---|---|
| вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча кизү торучы | 25 650 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Җайлаштырылган физик культура инструкторы | 26 600 |
| | Спорт инструкторы | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Җайлаштырылган физик культура буенча инструктор-методист | 26 610 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструкторы-методисты | |
| | Тренер | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструкторы-методисты | 26 620 |

2.2. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 27 390 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Инструктор-методист | 27 500 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | 27 650 |
| | Өлкән инструктор-методист | |

| | | |
|---|---|---|
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе структур бүлекчә мөдире (начальнигы) һәм башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы)(икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 27 830 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 27 890 |

2.3. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| "Урта медицина һәм фармацевтика персоналы" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медбрат) | 27 760 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медбрат) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы ( өлкән медбрат)<*> | 29 630 |
| "Табиблар һәм провизорлар" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 32 090 |
| "Югары медицина һәм фармацевтика белеме булган учреждениеләрнең структур бүлекчәләре җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)" профессиональ квалификация төркеме | | |

| | | |
|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә мөдире (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ. б.) (стационарларның хирургия профиле мөдиреннән тыш) | 35 370 |
| -------------------------------<br><br><*>Вазыйфа оешмада өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташлары (медбрат) буйсынуда булганда билгеләнә | | |

2.4. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа атамасы | Айлык база окладı күләме, сум |
|---|---|
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Билетлар тикшерүче (контролер) | 26 900 |
| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет кассалары мөдире | 27 450 |

## III. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгать нормасы

3.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

## IV. Бер шөгыльләнүче өчен Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары тренерларының хезмәтенә түләү нормативлары

4.1. Физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләренең физкультура-сәламәтләндерү төркемнәре һәм спорт секцияләре тренерларына хезмәте өчен түләү нормативы бер шөгыльләнүче өчен 2 процентка тигез кабул ителә.

4.2. Физкультура-сәламәтләндерү төркемнәре һәм спорт секцияләре тренеры хезмәте өчен түләү нормативы әлеге төркемнәрдә (секцияләрдә) бер тренер җитәкчелегендә шөгыльләнүче һәр ике ел саен укыган өчен 0,5 процентка арта.

## V. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

5.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары тренерының вазыйфаи оклады ( $O_d$ ) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \sum_{i=1}^{n} N_i,$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II булеге нигезендә кабул ителә торган тренерның база оклады күләме;

$N_i$ - әлеге Нигезләмәнең IV бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары тренерының хезмәте өчен түләү нормативлары.

5.2. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады (вазыйфаи оклад әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты нигезендә исәпләнә торган тренердан тыш)($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең база оклады күләме;

S - физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре били торган ставкаларның факттагы саны.

## VI. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

6.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрен стимуллаштыруга, хезмәтнең сыйфатлы нәтиҗәсенә юнәлдерелгән түләүләр, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүләр керә.

6.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;

мактаулы исемнәр, спорт исемнәре булган өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

авыл җирлегендә эшләгән өчен түләүләр;

хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр;

6.3. Физик культура хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм тәртибе.

6.3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$)физик культура хезмәткәрләренә гамәлдәге квалификация категорияләре булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – 1 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

1 нче таблица

**Физик культура хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләмнәре**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 2,5 |
| | югары квалификация категориясе | 3,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 3,0 |
| | югары квалификация категориясе | 4,3 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 3,8 |
| | югары квалификация категориясе | 5,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

6.3.2. Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре($B_{pz}$) булган өчен түләүләр физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр, спорт исемнәре булу өчен өстәмә түләүләр күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре, спорт исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Физик культура хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез була торган мактаулы исемнәр, спорт исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 4 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре булган өчен түләүләр күләме мактаулы исем, спорт исеме бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исем, ике һәм аннан күбрәк спорт исеме, булган физик культура хезмәткәрләренә аларның булуы өчен түләү физик культура хезмәткәр сайлап алган бер нигез буенча билгеләнә.

6.3.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стажга карап төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – 2 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме һәм һөнәри стандартлар буенча вазыйфаларның исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары | беренче – икенче | 2 елдан 5 елга кадәр | 1,25 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 1,75 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,25 |
| | | 15 елдан артык | 2,75 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфасы | беренче – өченче | 2 елдан 5 елга кадәр | 1,25 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 1,75 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,25 |
| | | 15 елдан артык | 2,75 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән , әгәр стажын раслый торган документлар физик культура һәм спорт муниципаль оешмада булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып башкарыла.

6.4. Мәгариф хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерендагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

6.4.1. Квалификация категориясе ($B_{kk}$) булган мәгариф хезмәткәрләренә түләүләр гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи окладі;

$D_{kk}$ – 3 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә

түләү күләме.

3 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| | югары квалификация категориясе | 7,5 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 7,5 |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 8,5 |
| | югары квалификация категориясе | 12,5 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| | югары квалификация категориясе | 15,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| | югары квалификация категориясе | 15,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

6.4.2. Мәгариф хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм тармак бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$)бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи окладды;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре, спорт исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы , Совет Социалистик Республикалар Союзы тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процентны тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының)тармак бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе Мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә.

"Мәгарифтәге казанышлар өчен" күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы Мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм тармак бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 1 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм тармак бүләкләре булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре бирелгән көннән башкарыла. Мәгариф хезмәткәрләренә ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исем, ике һәм аннан күбрәк спорт исеме, ике һәм аннан күбрәк тармак бүләгенә ия булган өчен түләү, мәгариф хезмәткәренең сайлавы буенча, мактаулы исемнәрнең берсе , спорт исемнәренең берсе һәм тармак бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

6.4.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ( $B_s$ ), профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стажга карап, төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи окладры;

$D_s$ – 4 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

4 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче – дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 1,5 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,25 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,75 |
| | | 15 елдан артык | 3,25 |
| Структур бүлекчәләрнең җитәкче вазыйфалары | беренче – икенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 1,5 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,25 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,75 |
| | | 15 елдан артык | 3,25 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән , әгәр стажын раслый торган документлар физик культура һәм спорт муниципаль оешмада булса,  яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып башкарыла.

6.4.4. Педагогика эше стажына 5 нче таблицада каралганча мәгариф һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкче һәм методик эш исәпкә алына.

5 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына шушында эшләгән вакыт исәпләнә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге**

| Оешманың исеме | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары белем бирү мәгариф оешмалары, югары белем бирү хәрби мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, белгечләргә өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү) оешмалары);<br>медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, балалар шифаханәләре, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б. | Укытучылар, мөгаллимнәр,укытучылар-дефектологлар, укытучылар-логопедлар (логопедлар), оештыручы укытучылар (тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә чакыру алды әзерлеге буенча), физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствога өйрәтү мастерлары (шул исәптән транспорт чараларын йөртү, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә өйрәтү, язу машинакаларда һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар( шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, класс тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар,өлкән әйдаманнар (пионервожатыйлар), физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (башлыклар, мөдирләр), уку-укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эшләре буенча, җитештерү(эш) буенча , чит тел буенча, җәйге укуга әзерлек буенча, гомуми белем бирү әзерлеге буенча, режим буенча директор (башлык, мөдир)урынбасарлары , уку-укыту бүлеге мөдирләре, практика , укыту-консультация пунктлары, логопед пунктлары, интернатлар, бүлекләрчәләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар мөдирләре (башлыклары)һәм эшчәнлекләре белем бирү (тәрбия) процессына, методик тәэмин итүгә бәйле башка структур бүлекчәләр; режим буенча өлкән дежурныйлар, аккомпаниаторлар, культоештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы |
| Барлык исемдәге (кайсы ведомствога каравына бәйсез рәвештә) методик (укыту-методик) оешмалар | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлек мөдирләре, эшчәнлекләре методик тәэмин ителеш белән бәйле фәнни хезмәткәрләр, өлкән методистлар, методистлар |

| | |
|---|---|
| Белем бирүгә идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары белән җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспектор, методик вазыйфалар, инструктор вазыйфалары, шулай ук башка вазыйфалар (икътисадый, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазыйфалардан тыш) |
| Производствода кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмалар, республика башкарма хакимият органнары бүлекчәләренең техник белем бирү бүлекләре (бюросы), кадрлар бүлекләре | Штаттагы укытучылар, эшчеләрне производствода өйрәтү мастерлары, эшчәнлекләре әзерләү һәм квалификация күтәрү мәсьәләләре белән бәйле булган җитәкче, инспектор, инженер вазыйфалары, методик вазыйфалар |
| РОСТО (ДОСААФ) һәм гражданнар авиациясе мәгариф оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструктор, инженер-инструктор, инструктор һәм укытучылар составлары, производствога өйрәтү мастерлары, инженер-инструктор-методистлар, инженер-очучылар-методистлар |
| Учреждениеләр, предприятие һәм оешмаларның тулай торактары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, мәдәни-агарту оешмалары һәм предприятиеләр һәм оешмаларның балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү бүлекчәләре | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белеме булган очракта, тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, өлкән инженер һәм җитештерү-техник белем бирү буенча өлкән инженер , өлкән мастер һәм җитештерү буенча мастер, өлкән инспектор һәм саклау һәм режим буенча инспекторы, уку-укыту-техник кабинет мөдире, психолог вазыйфаларында эшләү (хезмәт |

| | |
|---|---|
| | итү) |

| |
|---|
| Искәрмә:<br>Педагогик эш стажына түбәндәгеләр кертелә:<br>Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары, өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы медицина оешмаларында һәм оешмаларында укытучылар-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр булып эшләү вакыты;<br>башка учреждениеләрдә һәм оешмаларда эшләү вакыты, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында уку вакыты түбәндәге тәртиптә:<br>педагогик хезмәткәрләргә педагогик эш стажына бернинди шартларсыз һәм чикләүләрсез түбәндәгеләр кертелә:<br>контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакыты бер хәрби хезмәт көне бер эш көне исәбеннән, ә чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакыты - бер хәрби хезмәт көне ике эш көне исәбеннән;<br>фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты;<br>педагогик хезмәткәрләргә педагогик эш стажына, аерым-аерым алганда да, тулаем алганда да,  турыдан-туры шушы чорларга кадәр һәм алардан соң булган педагогик эшчәнлек алып барылган очракта, түбәндәге чорлар кертеп исәпләнә:<br>контракт һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, өлкән состав, прапорщиклар һәм мичманнар (шул исәптән ЭЭМ гаскәрләрендә, куркынычсызлык гаскәрләрендә һәм органнарында) вазыйфаларында хезмәт итү вакыты;<br>Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән (мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) хезмәткәрләре профсоюз территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларында, советларында) җитәкчелек итүче, инспектор, инструктор вазыйфаларында һәм белгечләрнең башка вазыйфаларында; профсоюз органнарында сайланулы вазыйфаларда;   педагогик җәмгыятьләрдә һәм Балалар фонды идарәләрендә инструктор һәм методист вазыйфаларында;   Укытучылар (халык мәгарифе, һөнәри техник белем бирү хезмәткәре) йорты директоры (мөдире) вазыйфасында;  балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яки  эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, балигъ булмаганнарның хокук бозуларын кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшләү вакыты |

6.4.5. СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә белем бирү оешмасында яки укытыла торган фән (курс, дисциплиналар, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча эшләү вакыты һәм хезмәт итү вакыты түбәндәге аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына кертеп исәпләнә:

укытучы-оештыручыларга (тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәргә әзерлек);

физик тәрбия укытучыларына һәм мөгаллимнәренә, физик тәрбия

җитәкчеләренә, физкультура буенча инструкторларга, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучыларга (өлкән тренер-укытучыларга);

хезмәткә (һөнәргә) өйрәтү, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус дисциплиналары укытучыларына, мөгаллимнәренә;

производствога өйрәтү осталарына;

өстәмә белем бирү педагогларына;

эксперименталь мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

педагог-психологларга;

методистларга;

мәдәният һәм сәнгать , музыка-педагогика, нәфис-графика, музыка урта звено (бүлекләре)белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә

балаларга өстәмә белем бирү оешмалары (мәдәният һәм сәнгать, шул исәптән музыка һәм сәнгать) укытучыларына, музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналары укытучыларына, педагогика училищеларының (педагогика колледжларының) музыка дисциплиналары укытучыларына, музыка укытучыларына, музыка җитәкчеләренә, концертмейстерларга.

6.4.6. Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләү вакыты, әлеге вазыйфаларда эшләгән чорда мәгариф хезмәткәренең педагогик белеме яки югары белем бирү оешмасында яки һөнәри белем бирү оешмасында укыса, педагогик эш стажына исәпләнә.

6.4.7. Мәгариф хезмәткәрләренә белем бирү оешмаларында сәгатьле түләү шартларында төп эштән тыш башкарыла торган педагогик эш вакыты,әгәр уку елында аның күләме (бер яисә берничә белем бирү оешмасында) 180 сәгатьтән дә ким булмаса, педагогик стажга кертелә.

Педагогик стажга бары тик педагогик эш башкарылган айлар гына исәпкә алына.

6.4.8. СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендәге учреждениеләрдә, оешмаларда эшләүнең һәм хезмәт итүнең эш профиленә, укытыла торган предметка (курска, дисциплинага, түгәрәккә)туры килүе турындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итү хокукы, профсоюз органы белән килештереп, мәгариф оешмасы җитәкчесенә бирелә.

6.5. Медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерендагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе:

6.5.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$)һөнәри-квалификация төркемнәреннән чыгып аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация

характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирү каралган белгечлекләр буенча эшләүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – 6 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

6 нчы таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

6.5.2. Медицина хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр өчен түләүләр($B_{pz}$) бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ -мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 3 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Медицина хезмәткәрләренә ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме булган өчен түләү, медицина хезмәткәрләренең сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.5.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр($B_s$), профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, медицина хезмәткәрләренә стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – 7 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

7 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |

| | | |
|---|---|---|
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән , әгәр стажын раслый торган документлар физик культура һәм спорт муниципаль оешмада булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып башкарыла.

6.6. Мәдәният хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм тәртибе.

6.6.1. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр( $B_{pz}$ ) мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ -мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 2 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, аларны биргән көннән башкарыла. Мәдәният хезмәткәрләренә ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме булган өчен түләү, мәдәният хезмәткәрләренең сайлавыннан чыгып , мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.6.2. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр( $B_s$ ), профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, мәдәният хезмәткәрләренә стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – 8 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

8 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 0,75 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,0 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 1,25 |
| | 15 елдан артык | 1,75 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү), стажны раслый торган документлар учреждениедә булган очракта, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкәннән соң яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

6.8. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә (укытучылар һәм преподавательләр вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) юбилей даталарына, аерым хөрмәт билгеләре, Рәхмәт хатлары, грамоталар, мактаулы исемнәр алуга һәм физик культура һәм спорт муниципаль оешмасының локаль норматив актларында һәм коллектив шартнамәләрендә билгеләнгән башка нигезләргә бәйле рәвештә төп эш

урыны буенча билгеле бер вакыт аралыгында (ай, квартал, ел) бер тапкыр бирелә.

6.8.1. Эш нәтиҗәләре буенча премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләрне башкару күләме, тәртибе һәм шартлары физик культура һәм спорт муниципаль оешмасының локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләре белән билгеләнә.

6.8.2. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фонды күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә (укытучылар вазыйфаларын биләүче физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләреннән тыш) окладлар (вазыйфаи окладлар), стимуллаштыру характерындагы түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

6.9. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы (укытучылар һәм преподавательләр вазыйфасын биләгән хезмәткәрләрдән тыш) билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып өстәмә физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

6.9.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының күрсәткече һәм түләүләрне башкару шартлары физик культура һәм спорт муниципаль оешма алдына куелган бурычларына нигезләнеп ел саен билгеләнә.

6.9.2. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләме, тәртибе һәм шартлары физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

6.9.3. Башкарыла торган эшләрнең ($B_{k_j}$) сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{k_j} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij}\times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij}\times K_i\right),$$

биредә:

$FOT_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$I_{ij}$ – j-нче хезмәткәр буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критерие;

$K_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүдәге i- критерийның чагыштырмача үлчәү коэффициенты;

n – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m - физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре саны.

6.9.4. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле күрсәткечле нәтиҗәлелек критерийларны чагыштыруны тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие (иң яхшы һәм иң начар) күрсәткечләре диапазонын сайлаудан гыйбарәт, аларның берсе нормалаштырылган критерийның нуль күрсәткеченә, икенчесе бергә туры килә. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы күрсәткече эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие күрсәткечләре диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие 0 алып 1 кадәр булган күрсәткеч белән бирелә. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы күрсәткече иң начар күрсәткечтән түбәнрәк булган очракта, нормалаштырылган критерийның күрсәткече 0, иң яхшысыннан югарырак булганда -1 дип кабул ителә.

6.9.5. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерий күрсәткеченең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткеченә бәйле булуы туры булырга мөмкин(уңай динамика критерий күрсәткече арту белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерий күрсәткече кимү белән билгеләнә) .

6.9.6. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие ($I_i$) критерий күрсәткеченә туры бәйлелектә булганда түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның факттагы күрсәткече;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң югары күрсәткече;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң түбән күрсәткече.

6.9.7. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие ($I_i$) критерий күрсәткеченә кире бәйлелектә булганда түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесының факттагы күрсәткече;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесының иң югары күрсәткече;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесының иң түбән күрсәткече.

6.9.7. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие ($I_i$) критерий күрсәткеченә кире бәйлелектә булганда түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

биредә $VK_i$ - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i-критерие үлчәү коэффициенты.

6.9.9. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме 11 - 15 таблицаларда күрсәтелгән.

11 нче таблица

**Физик культура хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| N т/б | Вазыйфа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң югары җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (1 нче төркем) | | | |
| 1.1. | Спорт залы буенча кизү торучы | беренче | 5 |
| 2. Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (2нче төркем) | | | |
| 2.1. | Спорт инструкторы | беренче | 45 |
| 2.2. | Җайлаштырылган физик культура инструкторы | беренче | 45 |
| 2.3. | Спортчы-инструктор | беренче | 45 |
| 2.4. | Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник | беренче | 45 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.5. | Җайлаштырылган физик культура буенча инструктор-методист | икенче | 50 |
| 2.6. | Физкультура-спорт оешмалары инструкторы-методисты | икенче | 50 |
| 2.7. | Тренер | икенче | 50 |
| 2.8. | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструкторы-методисты | өченче | 55 |

12 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| N т/б | Вазыйфа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң югары җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 1.1. | Физик культура буенча инструктор | беренче | 45 |
| 1.2. | Инструктор-методист | икенче | 50 |
| 1.3. | Методист | өченче | 55 |
| 1.4. | Өлкән инструктор-методист | өченче | 55 |
| 2. Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 2.1. | Балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе структур бүлекчә мөдире (начальнигы) һәм башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы)(икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | беренче | 65 |
| 2.2. | Балаларга белем бирү программасын һәм өстәмә белем | икенче | 70 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | | |

13 нче таблица

**Медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| N т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң югары җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1. | Шәфкать туташы (медбрат) | 40 |
| 1.2. | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медбрат) | 40 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.3. | Өлкән шәфкать туташы ( өлкән медбрат) | 50 |
| 2. Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |

14 нче таблица

**Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| N т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәү коэффициентларының иң югары җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Билетлар тикшерүче (контролер) | 5 |
| 2. Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Билет кассалары мөдире | 35 |

6.9.10. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары локаль актлар белән раслана.

6.9.11. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды ($FOT_k$) формалаша, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

$FOT_{do}$ - төп эш урыны буенча физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары буенча физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды;

$D_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фонды өлеше.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүгә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны буенча физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары буенча физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фондының 2 проценты күләмендә кабул ителә.

6.10. Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр($B_{sm}$) мәгариф хезмәткәрләренә, урта, әйдәп баручы звено һәм җитәкче составындагы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә, икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче физик культура хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$D_{sm}$ - авыл җирлегендә 1 388,5 сумга тигез эш өчен түләү күләме;

S - физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләре били торган ставкаларның факттагы саны.

6.11. Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр($B_{it}$) мәдәният, сәнгать һәм урта, әйдәп баручы звено һәм җитәкчелек составы хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә, икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация

төркемнәренә керүче физик культура хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ - хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 6 нчы таблицасында китерелгән.

## VII. Компенсация характерындагы түләүләр

7.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларында компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

зарарлы һәм (яки) куркыныч эш шартларында эшләүче физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр;

нормадан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен түләүләр (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) бергә үтәгәндә, эш сәгатеннән тыш, төнлә эшләгәндә һәм  һәм нормадан тайпыла торган башка шартларда эшләр башкарганда).

7.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә һәм Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең  хезмәт өчен түләү  фонды расланган чикләрендә күмәк килешүләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә.

7.3. Зарарлы һәм (яки) куркыныч эш шартларында эшләүче физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр ( $B_{kh}$ ) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$D_{kh}$ - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган компенсация характерындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ - законда компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт (ставка).;

$H_n$ - әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгать нормасы.

Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү нормаль хезмәт шартларында төрле эшләр өчен билгеләнгән окладлар (вазыйфаи окладлар), хезмәт хакы ставкалары белән чагыштырганда күбрәк күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә база окладының кимендә 4 проценты күләмендә билгеләнә.

7.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VIII. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләренең, җитәкче урынбасарларының һәм баш хисапчыларның хезмәт хакын билгеләү тәртибе

8.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

8.2. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи оклады ( $O_d$ ) гамәлгә куючы тарафыннан агымдагы елның 1 гыйнварына яисә хезмәт хакы буенча төркемгә бәйле рәвештә физик культура һәм спорт муниципаль оешмасын төзү датасына бер тапкыр билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

биредә:

$O_b$ - җитәкченең база оклады күләме;

S-асылда эшләнгән вакыт (ставкасы).

Физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесенең хезмәте өчен түләү төркеме муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең штат санына бәйле рәвештә билгеләнә.

8.3. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларының вазыйфаи окладлары әлеге оешмалар җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20 - 30 процентка түбәнрәк

билгеләнә.

8.4. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү төркеме һәм база оклады күләмнәре 16 нчы таблицада күрсәтелгән.

16 нчы таблица

**Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләренең база окладлары күләмнәре**

| Җитәкче хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең әһәмияте (хезмәткәрләрнең штат саны), кеше | База оклады, сум |
|---|---|---|
| 1 | 20 гә кадәр | 34 490 |
| 2 | 21 - 40 | 35 700 |
| 3 | 41 - 60 | 36 910 |
| 4 | 61 һәм аннан күбрәк | 37 510 |

8.5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесенә эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, ел саен, квартал саен, бер ел эшләү нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелә ала.

8.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләр , аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен , бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелә ала.

8.7. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары, баш хисапчылары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары локаль актлар белән раслана.

8.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{vk},$$

биредә:

$B_c$ - физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесе (җитәкче урынбасарлары, баш хисапчы) вазыйфаи окладының 10 процентына тигез кабул ителә торган стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме;

$K_{vk}$ - сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

8.9. муниципаль физик культура һәм спорт оешмасы җитәкчесенә (җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга)хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр ($B_{it}$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының, баш хисапчының) вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ - хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 6 нчы таблицасында китерелгән.

8.10. Компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә физик культура һәм спорт муниципаль оешмасының җитәкчесе, җитәкче урынбасарлары, баш хисапчысы өчен билгеләнә.

## IX. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының хезмәте өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

9.1. Физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының хезмәте өчен түләү фондын формалаштыру норматив чыгымнар, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

9.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны исәпләү, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә ( гомуми тармак һөнәрләре эшчеләрен, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләрен , җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең гомуми тармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп), агымдагы финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яисә физик культура һәм спорт муниципаль оешмасының бюджет сметасында каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

9.3. Финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, физик культура һәм спорт

муниципаль оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән , хезмәт хакы түләү фонды экономиясе икътисады тиешле чор (ай, квартал, ел) өчен ,әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының локаль норматив актлары нигезендә, бүләкләү рәвешендәге түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономияләнгән очракта, бүләкләү рәвешендәге түләүләр хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә. ( җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең гомуми тармак вазыйфалары, эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомуми тармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп).

Тиешле чорда хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы хезмәткәренә бүләкләү рәвешендәге түләүләр күләме , шушы чор өчен хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып башкарылган хезмәт өчен түләү күләме "Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында" 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда агымдагы елның 1 гыйнварына билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч тапкыр минималь күләменнән арта алмый (физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләреннән тыш).

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә бүләкләү рәвешендәге түләүләр күләме физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары җитәкчеләренә гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр хисабыннан физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләүдән файдалану өчен җаваплылык физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларының җитәкчеләренә йөкләнә.

Зеленодольск муниципаль районы
физик культура һәм спорт
муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары турындагы
нигезләмәгә
кушымта

1 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм тармак бүләкләре булган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган әлеге бүләкләр исемлеге**

| N т/б | Мактаулы исем, спорт исеме һәм тармак бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |

| | |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык укытучысы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең Атказанган производствога өйрәтү остасы |
| 1.6. | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7. | Россиянең Атказанган спорт мастеры |
| 1.8. | Россиянең Атказанган тренеры |
| 1.9. | Россиянең Атказанган  халыкара класслы спорт остасы |
| 1.10. | Россиянең халыкара класслы спорт остасы |
| 1.11. | Россия спорт мастеры |
| 1.12. | Россия гроссмейстеры |
| 1.13. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 2. Совет Социалистик Республикалар  Союзының (РСФСР) мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 2.1. | СССРның Халык укытучысы |
| 2.2. | СССРның Атказанган спорт остасы |
| 2.3. | СССРның Атказанган тренеры |
| 2.4. | СССРның спорт остасы |
| 2.5. | СССРның халыкара класслы спорт остасы |
| 2.6. | СССР гроссмейстеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2. | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 3.5. | Атказанган тренер |
| 3.6. | Атказанган мәктәп укытучысы |

| | |
|---|---|
| 3.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү остасы |
| 3.9. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10. | Атказанган укытучы |
| 3.11. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.12. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.13. | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 3.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 3.15. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү остасы |
| 4.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.9. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.11. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.13. | Атказанган тренер |
| 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 5.2. | Татарстан Республикасының Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3. | Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы |
| 5.4. | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5. | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| 5.6. | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 5.7. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8. | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| Тармак бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2. | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.7. | Россия Федерациясенең физик культура һәм спорт мактаулы хезмәткәре |
| 2. СССР Халык мәгарифе министрлыгы (РСФСР), СССРның Мәгариф министрлыгы (РСФСР) | |
| 2.1. | «СССРның мәгариф отличнигы» билгесе |
| 2.2. | «Халык мәгарифе отличнигы» билгесе |
| 2.3. | «СССРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2.4. | «РСФСР һөнәри техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2.5. | «Физик культура һәм спорт отличнигы» билгесе |

2 нче таблица

**Мәдәният хезмәткәрләренә мактаулы исемнәре булган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган әлеге бүләкләр исемлеге**

| N т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |

| | |
|---|---|
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6. | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның Халык артисты |
| 3.2. | СССРның Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган пропагандачы |
| 4.2. | Халык артисты |
| 4.3. | Атказанган артист |
| 4.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5. | Халык рәссамы |
| 4.6. | Атказанган рәссам |
| 4.7. | Халык язучысы |
| 4.8. | Атказанган язучы |
| 4.9. | Халык шагыйре |
| 4.10. | Халык җырчысы |
| 4.11. | Халык акыны |
| 4.12. | Атказанган журналист |
| 4.13. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.15. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| 4.16. | Атказанган китапханәче |
| 4.17. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.18. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Халык артисты |
| 5.2. | Атказанган артист |
| 5.3. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.4. | Халык рәссамы |
| 5.5. | Атказанган рәссам |
| 5.6. | Халык язучысы |
| 5.7. | Атказанган язучы |
| 5.8. | Халык шагыйре |
| 5.9. | Атказанган журналист |
| 5.10. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.11. | Атказанган китапханәче |
| 5.12. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |

3 нче таблица

**Медицина хезмәткәрләренә мактаулы исемнәре булган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган әлеге бүләкләр исемлеге**

| N т/б | Мактаулы исем атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |

4 нче таблица

**Физик культура хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр, спорт исемнәре булган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган әлеге бүләкләр исемлеге**

| N т/б | Мактаулы исем, спорт исеме исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.2. | Россиянең Атказанган спорт мастеры |
| 1.3. | Россиянең Атказанган тренеры |
| 1.4. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 1.5. | Россиянең Атказанган халыкара класслы спорт остасы |
| 1.6. | Россиянең халыкара класслы спорт остасы |
| 1.7. | Россия спорт мастеры |
| 1.8. | Россия гроссмейстеры |
| 1.9. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның Атказанган спорт остасы |
| 3.2. | СССРның Атказанган тренеры |
| 3.3. | СССРның спорт остасы |
| 3.4. | СССРның халыкара класслы спорт остасы |
| 3.5. | СССРның Атказанган тренеры |
| 3.6. | СССР гроссмейстеры |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 4.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |

| | |
|---|---|
| 4.4. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.5. | Атказанган тренер |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.2. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 24 февралендәге
631 номерлы карарына
2 нче кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ ОЕШМАЛАРЫ ҖИТӘКЧЕЛӘР, БЕЛГЕЧЛӘР ҺӘМ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ГОМУМТАРМАК ВАЗЫЙФАЛАРЫНЫҢ, ЭШЧЕЛӘР, МӘДӘНИЯТ, СӘНГАТЬ ҺӘМ КИНЕМАТОГРАФИЯ ЭШЧЕЛӘРЕ ГОМУМТАРМАК ҺӨНӘРЛӘРЕНЕҢ ҺӨНӘРИ КВАЛИФИКАЦИЯСЕ ТӨРКЕМНӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары (алга таба - физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы) җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазифаларының, эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификациясе төркемнәре хезмәткәрләре окладларын формалаштыру тәртибен , компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын тәгаенлый.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы- физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы хезмәткәрләренең хезмәте өчен федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән база окладлары, хезмәт хакының база ставкалары, вазыйфаи окладлар күләмен дә кертеп, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

